Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советының егерме җиденче утырышы

Шәле авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

29 май, 2020 ел № 68

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы) Шәле бермандатлы сайлау округларына түбәндәге йортларны кертеп төгәлләштерергә:

а) Шәле № 5 бермандатлы сайлау округына Вахитов урамы буенча 74 нче йорт;

б) Шәле № 6 бермандатлы сайлау округына БКШ (СНТ) Алмагач, БКШ (СНТ) Мёша-1, БКШ (СНТ) Мёша-4;

в) Шәле № 7 бермандатлы сайлау округынагы

- «К.Йолдыз урамы» сүзләрен «Кызыл Йолдыз урамы буенча 1-32 номерлы йортлар» сүзләренә алмаштырырга;
- «Һ.Такташ» сүзләрен «Һади Такташ» сүзләренә алмаштырырга;
- «М.Җәлил» сүзләрен «Муса Җәлил» сүзләренә алмаштырырга.

г) Шәле № 8 бермандатлы сайлау округынагы «К.Йолдыз урамы» сүзләрен «Кызыл Йолдыз» сүзләренә алмаштырырга;

д) Шәле № 9 бермандатлы сайлау округынагы «Һ. Такташ урамы буенча 38-82 нче йортлар, М. Җәлил урамы буенча 29-57 нче йортлар, Дуслык урамы буенча 58-79 нчы йортлар)» сүзләрен «(Һади Такташ урамы буенча 38-84 нче йортлар, Муса Җәлил урамы буенча 29-58 нче йортлар, Дуслык урамы буенча 58-81 нче йортлар)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Шәле авыл җирлеге башлыгы — И.Р. Әхмәтҗанов

СОВЕТ ШАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ